Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Званка авылы
Чокыр урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

12 октябрь, 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Чокыр урамы гражданнары җыенының 2024 елның 12 октябрендәге беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

1«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Кощаково авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар җыены: «Сез 2025 елда Кощаково авыл җирлеге Званка авылы Чокыр урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Чокыр ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **узмаган дип санарга кирәк**.

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова